# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

## Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге Каенсар авылында халык җыены нәтиҗәләре турында

**17 ноябрь 2022 ел** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2022 елның 17 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән халык җыены нәтиҗәсе белән халык җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез 2023 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге Каенсар авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 250 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 1нче группа инвалидлардан, 70 яшьтән узган гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны (контракт буенча хәрби хезмәткәрләрне, мобилизацияләнгән, үз ихтыяры белән махсус хәрби операциядә катнашкан затларны) һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы?

- юл-урам челтәре нигезен вак таштан каплау, Каенсар авылы, төп юлдан Югары урамның 4 нче йортына кадәр».

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучы сайлау хокукына ия затлар исемлегенә 119 граждан, тавыш бирүдә катнашкан 64 граждан кертелде.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде: «Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 59 кеше тавыш бирде; «Каршы» позициясе өчен җыенда катнашучы 5 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Арча муниципаль район Яңасала авыл җирлеге Каенсар авылында халык җыены узды, җыен нәтиҗәләре дөрес дип танырга.
2. «Сез 2023 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге Каенсар авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 250 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 1нче группа инвалидлардан, 70 яшьтән узган гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны (контракт буенча хәрби хезмәткәрләрне, мобилизацияләнгән, үз ихтыяры белән махсус хәрби операциядә катнашкан затларны) һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын,

хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы?

- юл-урам челтәре нигезен вак таштан каплау, Каенсар авылы, төп юлдан Югары урамның 4 нче йортына кадәр»

- соравы буенча карар кабул ителде дип санарга.

3. Әлеге карарны кабул ителгән көннән 7 көн эчендә, ТР, Арча районы, Каенсар авылы, Урта урам, 25 йорт адресы буенча мәгълүмат стендында, Арча муниципаль районның (http://arsk.tatarstan.ru) рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Арча муниципаль районы
Яңасала авыл җирлеге башлыгы Сафин А.И.